КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 март г.Казань № 215

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 908 нче карары белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 908 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче; 2016 ел, 18 июнь, 414 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 834 нче; 2018 ел, 30 июль, 618 нче; 2020 ел, 18 май, 402 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1181 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә, 9 пункт таблицасындагы 15 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Вәкаләтле медицина оешмасының гражданга яки социаль хезмәтләр күрсәтелүчегә өйдә социаль хезмәт күрсәтү формасында яки ярым стационар формада яки стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүдән баш тарту (шул исәптән

вакытлыча) өчен зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булу яисә мондый зарарлы булуын күрсәтә торган медицина билгеләре булмау турында бәяләмәсе».

2. Бу карар 2023 елның 20 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин